ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

8 июнь 2018 ел № 3283

Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатында Яр Чаллы шәһәренең муниципаль предприятиеләренә, учреждениеләренә (оешмаларына) исемнәр бирү, аларның исемнәрен алмаштыру тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, дәүләт, республика, шәһәр үсешенә әһәмиятле өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турында истәлекне саклау максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен алмаштыру тәртибе турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карап тикшерү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 8 июнендәге
3283 нче карарына
1 нче кушымта

## Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатында Яр Чаллы шәһәренең муниципаль предприятиеләренә, учреждениеләренә (оешмаларына) исемнәр бирү, аларның исемнәрен алмаштыру тәртибе турында нигезнамә

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен алмаштыру тәртибе турында нигезнамә (алга таба – нигезнамә, муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исем бирү) Башкарма комитет тарафыннан төзелгән муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) күрсәтелгән затларның, вакыйгаларның исемнәрен бирү юлы белән гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү кагыйдәләрен һәм тәртибен билгели.

2. Нигезнамә түбәндәге мәсьәләләрне җайга салмый:

1) гражданнар законнары таләпләре нигезендә муниципаль предприятиеләр оештырганда аларга исемнәр бирүне;

2) Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү максатында муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирүне;

3) күренекле галимнәр истәлеген мәңгеләштерү максатында муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирүне;

4) гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгаларның исемнәрен бирү сәбәпле, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр (оешмалар) биналарына мемориаль (истәлек) такталар урнаштыруны.

3. Сәяси репрессияләр корбаннары дип танылган затлар истәлеген мәңгеләштерү максатында муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү мәсьәләләрен нигезнамә белән җайга салганда, Россия Федерациясенең «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 нче Законында билгеләнгән нигезләмәләр исәпкә алына.

4. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү дәүләт, республика, Яр Чаллы шәһәре һәм (яки) башка иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсешенә әһәмиятле өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турында истәлекне саклау максатында гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә түбәндәгеләрнең исемнәре бирелә:

1) дәүләт, сәяси, һәм җәмәгать эшлеклеләре, дәүләт һәм (яки) җәмгыять, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы үсешенә керткән әһәмиятле өлеше (йогынтысы) рәсми танылган яки гомумтанылган башка гражданнар, оешмалар (тарихи вакыйгалар);

2) икътисад (шул исәптән сәнәгать, авыл хуҗалыгы, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм башка өлкәләр), сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт, сәнгать, белем һәм мәгариф, социаль яклау, үсеп килүче буынны тәрбияләү, Яр Чаллы шәһәрендә хәйрия эшчәнлеге үсешенә әһәмиятле өлеш керткән күренекле гражданнар;

3) хезмәт, иҗтимагый, һөнәри һәм башка эшчәнлеге Яр Чаллы шәһәреннән читтә абруй һәм иҗтимагый ихтирам казанган Яр Чаллы шәһәрендә туган күренекле кешеләр;

4) Яр Чаллы шәһәре үсешенә әһәмиятле йогынты ясаган күренекле тарихи вакыйгалар;

5) Яр Чаллы шәһәре үсешенә, аның абруен күтәрүгә әһәмиятле өлеш керткән күренекле оешмалар.

6. Муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү турында карар Башкарма комитет карары белән кабул ителә.

## 2 бүлек. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү кагыйдәләре

7. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү хәзерге рус әдәби теле нормаларын (исемнәр татар телендә бирелгән очракта – татар әдәби теле нормаларын) саклап гамәлгә ашырылырга тиеш.

8. Бер үк исемне ике яки берничә муниципаль предприятиегә яки учреждениегә бирү рөхсәт ителми.

9. Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең исемнәрен алмаштыру, элек бер үк затның, оешманың һәм тарихи вакыйганың исеме ике яки берничә муниципаль предприятиегә яки учреждениегә бирелгән һәм хуҗалык яки башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруга кыенлык тудырган очракта, шулай ук аерым муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә элек бирелгән (тарихи) исемнәрен кире кайтару максатында рөхсәт ителә.

10. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең, Нигезнамәнең 5 пунктында күрсәтелгән башка затларның исемнәре, күрсәтелгән затлар вафат булганнан соң бирелә.

11. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү турында карар кабул иткәндә, Нигезнамәнең 5 пунктында күрсәтелгән затларның якын туганнарының (булган очракта) муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү юлы белән истәлекне мәңгеләштерү мөмкинлеге турында фикере исәпкә алына.

12. Исемен мәңгеләштерүгә тәкъдим ителә торган вакыйганың яки затның әһәмиятлелеген объектив бәяләү максатында предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) исеме мәңгеләштерелә торган зат вафат булганнан соң 5 ел узгач;

2) истәлеккә исеме бирелә торган вакыйга булганнан соң 10 ел узгач.

Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларындагы нигезләмәләр предприятиеләргә һәм учреждениеләргә Советлар Союзы Геройларының, Россия Федерациясе Геройларының, Социалистик Хезмәт Геройларының, Россия Федерациясе хезмәт Геройларының, Дан ордены белән бүләкләнгән гражданнарның, «Ватан каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнгән гражданнарның, «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнгән гражданнарның исемнәре бирелгән очракларга кагылмый.

13. Исемен муниципаль предприятиегә яки учреждениегә бирү күздә тотылган гражданның туганнары, күрсәтелгән исемне бирү инициативасы белән чыга алмыйлар.

## 3 бүлек. Карарлар кабул итү тәртибе

14. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү инициаторлары булып дәүләт хакимияте органнары, Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хезмәт коллективлары һәм иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук саны 20 кешедән ким булмаган гражданнарның инициаторлар төркемнәре (алга таба – инициаторлар) чыга ала. Инициаторлар төркемендә катнашучылар санының яртысыннан күбесе Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр булырга тиеш, аның составына Нигезнамәнең 13 пунктында күрсәтелгән затлар керергә тиеш түгел.

15. Инициаторлар Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыралар:

1) исем бирү нигезләрен бәян итеп, инициатор турында мәгълүматлар булган юллама (юридик затлар өчен – юридик затның исеме, юридик адресы һәм элемтә телефоны; физик затлар өчен – гражданнарның фамилияләре, исемнәре, аталарының исеме, яшәү урынының адресы, паспорт мәгълүматлары, элемтә телефоннары);

2) исеме мәңгеләштерелә торган вакыйганың яки затның казанышлары дөреслеген раслаучы архив документларының яки башка документларның күчермәләре;

3) исем бирелә торган муниципаль предприятие яки учреждение турында мәгълүмат булган документлар, шул исәптән:

- гамәлдәге исеме, урнашу урыны (адресы), юридик адресы;

- җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә мәгълүматлары;

- предприятиенең (учреждениенең) күренекле зат, оешма яки тарихи вакыйга исемен бирүгә лаеклы булуын раслаучы мәгълүматлар;

4) исем бирү күздә тотылган муниципаль предприятие (учреждение, оешма) җитәкчесенең инициатива белән килешү яки килешмәү турында язма рәвештә (ирекле формада) белдерелгән фикере.

16. Башкарма комитет юллама һәм теркәлгән документлар кергән көнне аларны теркәү һәм исәпкә алуны гамәлгә ашыра, теркәлгәннән соң 5 эш көне эчендә күрсәтелгән документларны әзерли һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карап тикшерү буенча комиссиягә (алга таба – комиссия) җибәрә.

17. Башкарма комитетка тулы булмаган документлар комплекты яисә нигезнамәнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документлар кергән очракта, күрсәтелгән документлар Башкарма комитетта теркәлгән көннән башлап 10 эш көненнән дә соңга калмый, җитешсезлекләрне бетерү тәкъдиме белән инициаторларга кире кайтарыла. Инициатор, күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән соң, юллама белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шулай ук документлар нигезнамәнең 31 пунктының икенче абзацында күздә тотылган нигезләр буенча инициаторга кире кайтарыла.

18. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

19. Комиссиянең кимендә өчтән бер өлешен Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, хезмәткәрләре яки эшчеләре булып исәпләнмәгән җәмәгатьчелек вәкилләре тәшкил итәргә тиеш.

20. Комиссия рәисе булмаган вакытта, аның кушуы буенча аның эшен комиссия рәисе урынбасары оештыра.

21. Комиссия әгъзаларының яртысыннан күбесе катнашкан очракта, аның утырышлары тулы хокуклы санала.

22. Комиссия утырышлары эшендә инициаторларның (инициаторлар вәкилләренең) катнашуы тәэмин ителә.

23. Комиссиянең беренче утырышы Башкарма комитетта юллама теркәлгән көннән башлап 10 эш көненнән дә соңга калмый үткәрелә. Комиссиянең йомгаклау утырышы Башкарма комитетта юллама теркәлгән көннән башлап 20 календарь көннән дә соңга калмый үткәрелә. Йомгаклау карары комиссиянең беренче утырышы барышында кабул ителергә мөмкин.

24. Комиссия түбәндәгеләрне алып бара:

1) муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү турында материалларны кабул итү, карап тикшерү;

2) түбәндәгеләрне чагылдыру тулылыгы буенча тапшырыла торган материалларга карата таләпләр билгеләү:

- күренекле гражданнарның тормыш юлын һәм казанышларын;
- тарихи вакыйгаларның дөреслеген;
- предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның ролен;

3) кергән материаллар һәм документларны карап тикшерү йомгаклары буенча комиссия утырышы беркетмәсен әзерләү.

25. Комиссия карарлары комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы буенча кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

26. Тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәсендә комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) юлламаны хупларга;

2) юлламаны кире кагарга.

27. Комиссия утырышларының беркетмәләре карарлар чыгарганда исәпкә алынырга тиеш.

28. Комиссия тарафыннан муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү мөмкинлеге турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитетның тармак органы тарафыннан, комиссия утырышы беркетмәсен теркәп, Башкарма комитетның муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү турында карар проекты әзерләнә.

29. Комиссия тарафыннан муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү өчен нигезләр булмау турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитетның тармак органы тарафыннан, комиссия утырышы беркетмәсен теркәп, Башкарма комитетның муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирне кире кагу турында карар проекты әзерләнә.

30. Башкарма комитетның муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү турында карары Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм Башкарма комитетта юллама теркәлгән көннән башлап 30 календарь көннән артмаган срокта бастырыла.

31. Муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирүне кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет 3 эш көне эчендә, инициаторга кабул ителгән карар турында белдерү кәгазе җибәрә.

Инициатор Башкарма комитетка шул ук мәсьәлә буенча юллама белән кимендә өч елдан соң кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет<br>
Аппараты Җитәкчесе                                        Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 8 июнендәге
3283 нче карарына
2 нче кушымта

Күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карап тикшерү буенча
комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Харисов Винер Хәмит улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 3. | Касыймова Рәхимә Равил кызы | комиссиянең җаваплы секретаре, Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең оештыру-педагогик тәэмин итү һәм социаль яклау бүлеге башлыгы |
| | комиссия әгъзалары: | |
| 4. | Айкин Виктор Сидимирович | Яр Чаллы шәһәренең «76 нчы гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы (килешенү буенча) |
| 5. | Галимов Искәндәр Нургаләм улы | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |
| 6. | Иванова Венера Бәхтегәрәй кызы | Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешенү буенча) |
| 7. | Канеев Билял Абдрахман улы | «Яр Чаллы шәһәре тарихы музее» МАМУ һәйкәлләрне саклау буенча өлкән фәнни хезмәткәре (килешенү буенча) |
| 8. | Кислов Александр Иванович | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| 9. | Мостафина Фәйрүзә Зөфәр кызы | мәгарифне үстерү мәсьәләләре буенча шәһәр Хакиме киңәшчесе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешенү буенча) |
| 10. | Насрединов Роман Мансур улы | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы |
| 11. | Ногманова Эльвира Илшат кызы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 12. | Рзаева Гөлзада Мөхәммәтгәрәй кызы | «Энергетик» мәдәният сарае» МАМУ директоры, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешенү буенча) |
| 13. | Усманова Раушан Мәсгут кызы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |
| 14 | Хөсәенов Уел Галим улы | Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ